| | |
|---|---|
| АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«15» февраля 2016г. № 14/2лс

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы инвестицион агентлыгының дәүләт гражданнары хезмәткәрләренең яллаучысы вәкиленә ул үтәгән вазыйфага бәйле йөкләмәләрне үтәгәндә барлыкка килгән яки барлыкка килергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләргә бәйле низаглар турында белдерү тәртибе турында

2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы гамәлләр турында»гы Федераль закон, «Россия Федерациясендәге дәүләт хезмәте биләүчеләрнең, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын үтәүчеләрнең һәм башка хезмәткәрләрнең үз вазыйфасына бәйле йөкләмәләрне үтәгәндә барлыкка килгән яки барлыкка килергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләргә бәйле низаглары, һәм Россия Федерациясе Президенты актына кертелергә тиешле кайбер үзгәрешләр турында хәбәр итү тәртибе» буенча 2015 елның 22 декабрендә 650нче номер белән теркәлгән Россия Федерациясе Президенты Указы белән бәйле рәвештә һәм коррупциягә каршы торыр өчен кулланылган чараларның үтемлелеге максатында

б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы инвестицион агентлыгының дәүләт гражданнары хезмәткәрләренең яллаучысы вәкиленә ул үтәгән вазыйфага бәйле йөкләмәләрне башкарганда барлыкка килгән яки барлыкка килергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләргә бәйле низаглар турында белдерү тәртибен расларга.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Т.И.Миңнуллина

Татарстан Республикасы

Инвестицион үсеш агентлыгының

«___» ____________ 20__ ел

№ _____

Боерыгы белән расланды

**ТӘРТИП**

Татарстан Республикасы инвестицион агентлыгының дәүләт гражданнары хезмәткәрләренең яллаучысы вәкиленә ул үтәгән вазыйфага бәйле йөкләмәләрне үтәгәндә барлыкка килгән яки барлыкка килергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләргә бәйле низаглар турында белдерү буенча

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы инвестицион агентлыгының дәүләт гражданнары хезмәткәрләренең яллаучысы вәкиленә (алга таба, билгеләнелгәнчә – Тәртип, дәүләт гражданнары хезмәткәрләре) ул үтәгән вазыйфага бәйле йөкләмәләрне үтәгәндә барлыкка килгән яки барлыкка килергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләргә бәйле низаглар турында хәбәр итү процедурасын билгели.

2. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелүчеләр, йөкләмәләрне үтәгәндә барлыкка килгән яки барлыкка килергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләргә бәйле низагларга каршы кулланылырга тиешле чараларны күздә тоткан биләгән вазыйфалары һәм аларның яллаучысының вәкиле булып торучы ТР Инвестицион үсеш агентлыгының Җитәкчесе (алга таба – Агентлык), Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законына бәйле рәвештә, вазыйфага бәйле йөкләмәләрне үтәгәндә барлыкка килгән яки барлыкка килергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләргә бәйле низаглар турында хәбәр итәргә һәм аларны җайга салу буенча барлык чараларны да күрергә бурычлы.

3. Граждан хезмәткәренең вазыйфасына бәйле йөкләмәләрне үтәгәндә шәхси мәнфәгатьләргә бәйле низаглар китереп чыгарырдай кызыксынуы барлыкка килгән очракта ул кичекмәстән бу хакта хәбәр итәргә тиеш. Әгәр әлеге вакытта ул эш урынынннан читтә, яисә вазыйфасы буенча командировкада булса, шунда ук Агентлык Җитәкчесенә шәхси мәнфәгатьләр нигезендә барлыкка килгән яки барлыкка килергә мөмкин низаг турында хат белән белдерергә бурычлы.

4. Барлыкка килгән яки барлыкка килергә мөмкин шәхси мәнфәгатьләр нигезендәге низаг турындагы белдерүне (алга таба – Белдерү) Тәртипнең 1нче номерлы кушымтасында күрсәтелгән форма буенча хат рәвешендә төзергә кирәк.

5. Граждан хезмәткәре белдерүне Агентлык Җитәкчесе исеменә төзи һәм аны Агентлыктагы коррупция һәм башка хокук бозуларны булдырмау өчен җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) юллый.

6. Белдерүләр җаваплы зат тарафыннан Тәртипнең 2нче номерлы кушымтасындагы форма буенча төзелгән һәммә белдерүләр теркәлә торган Журналда алынган көнендә теркәлеп куелырга тиеш. Журнал битләренең тегелгән, номерланган һәм Агентлык мөһере белән расланган булуы зарур.

Белдерүнең теркәлгән булуын дәлилләүче мөһер куелган күчермәсе граждан хезмәткәренә теркәлгән көнне үк тапшырылырга тиеш.

7. Җаваплы зат теркәлүдән соң икенче көнне, аннан да озакка сузмыйча, Агентлык Җитәкчесенә яки Агентлыкның белдерүләр буенча җаваплы вәкиленә белдерүнең теркәлүе турында хәбәр итәргә һәм беренче карауны уздырырга тиеш.

8. Белдерүнең беренче каралышы барышында җаваплы зат белдерүне юллаган граждан хезмәткәреннән рәсми хатта күрсәтелгән шартлар буенча аңлатмалар алырга, дәүләт хакимияте оешмаларына, яисә башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм бу эшкә кагылышы булган бүтән оешмаларга запрос ясауның билгеләнгән тәртибе буенча юллама җибәрүне оештырырга мөмкин.

9. Белдерүнең беренче каралышында чыгарылган нәтиҗәләр буенча җаваплы зат мотивацияле йомгак – нәтиҗә ясый. Беренче каралыш барышында алынган белдерү үзе, нәтиҗә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан белдерү алынганнан соң җиде эш көне дәвамында Агентлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаларын үтәгәндәге тотышы һәм шәхси мәнфәгатьләр нигезендә барлыкка килгән низагларны җайга салу буенча эш алып баручы Комиссия рәисенә (алга таба – Комиссия) тапшырылырга тиеш.

10. Әлеге Тәртипнең 8нче пунктында крсәтелгән белдерү буенча запрос җибәрелгән очракта, белдерү үзе, нәтиҗә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан белдерү алынганнан соң 45 көн дәвамында Комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт Комиссия рәисе тарафыннан 30 көнгә озайтылырга мөмкин, әмма аннан да артыкка түгел.

11. Белдерү, нәтиҗә һәм башка материаллар ТР Инвестицион үсеш агентлыгының 15.02.2016 №1302/2лс. номеры астында ТР Инвестицион үсеш агентлыгының Приказында расланган дәүләт гражданнары хезмәткәрләренең вазыйфаларын үтәгәндәге тотышы һәм шәхси мәнфәгатьләр нигезендә барлыкка килгән низагларны җайга салу буенча таләпләре күрсәтелгән Комиссия Положениесе нигезендә карала.

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгының
дәүләт гражданнары
хезмәткәрләренең яллаучысы
вәкиленә ул үтәгән вазыйфага бәйле
йөкләмәләрне үтәгәндә барлыкка
килгән яки барлыкка килергә мөмкин
булган шәхси мәнфәгатьләргә бәйле
низаглар турында белдерү Тәртибенә
1нче номерлы Кушымта

ТР Инвестицион үсеш
агентлыгының җитәкчесенә
_________________________________

кемнән___________________________
_________________________________
_________________________________
____
(Ф.И.О., граждан дәүләт хезмәткәренең вазыйфасы,
яшәү урыны, телефоны)

# БЕЛДЕРҮ

вазыйфага бәйле йөкләмәләрне үтәгәндә шәхси мәнфәгатьләр нигезендә низаг барлыкка китергән яки барлыкка китерергә мөмкин булган

шәхси кызыксыну турында

Сезгә вазыйфага бәйле йөкләмәләрне үтәгәндә шәхси мәнфәгатьләр нигезендә низаг барлыкка китергән яки барлыкка китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуымның булуы турында хәбәр итәм (кайсы очрак икәнлеген күрсәтеп, тиешлесенең астына сызарга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булган шартлар:____________________________________________________
_____________________________________________________________

Үтәлешенә шәхси кызыксыну йогынты ясый алган яки ала торган вазыйфа буенча йөкләмәләр: ________________________________________
_____________________________________________________________

Шәхси мәнфәгатьләр низагына юл куймау яисә аны җайга салу буенча күрсәтелгән чаралар: ____________________________________________________

_________________________________________________________________________

ТР Инвестицион агентлыгының дәүләт гражданнары хезмәткәрләренең вазыйфаларын үтәгәндәге тотышы һәм шәхси мәнфәгатьләр нигезендә барлыкка килгән низагларны җайга салу буенча эш алып баручы Комиссиясенең утырышында булырга ниятлим/ниятләмим (кайсы тиешле, шунысының астына сызырга)

_________________________________________
(дата, имза, инициаллар һәм фамилия)

Теркәлү: N_______________ "____"_____________20 ___ ел.

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш
агентлыгының дәүләт
гражданнары
хезмәткәрләренең
яллаучысы вәкиленә ул
үтәгән вазыйфага бәйле
йөкләмәләрне үтәгәндә
барлыкка килгән яки
барлыкка килергә мөмкин
булган шәхси
мәнфәгатьләргә бәйле
низаглар турында белдерү
Тәртибенә 2нче номерлы
Кушымта

Шәхси мәнфәгатьләргә бәйле барлыкка килгән яки барлыкка килергә мөмкин булган низаг турында белдерүләрне теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Белдерүнең номеры һәм датасы (белдерү талоны датасы белән номеры күрсәтелә) | Белдерү юллаган дәүләт граждан хезмәткәре турында мәгълүмат | | | | Белдерүнең кыскача эчтәлеге | Белдерүне кабул иткән затның Ф.И.О. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Ф.И.О. | Шәхесен раслаучы документ; вазыйфасын раслаучы таныклык | Вазыйфасы | Элемтә өчен телефоны | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |